**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында электр тәэминаты куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча штаб төзү турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында электр тәэминаты куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча штаб төзү турында» 2008 елның 12 июлендәге ПУ-324 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 27 ноябрендәге ПУ-615 номерлы, 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-209 номерлы, 2009 елның 13 ноябрендәге ПУ-605 номерлы, 2010 елның 1 февралендәге ПУ-36 номерлы, 2010 елның 20 августындагы ПУ-546 номерлы, 2011 елның 7 февралендәге ПУ-48 номерлы, 2013 елның 16 декабрендәге ПУ-1233 номерлы, 2014 елның 8 ноябрендәге ПУ-1023 номерлы, 2016 елның 23 гыйнварындагы ПУ-26 номерлы һәм 2016 елның 13 октябрендәге ПУ-917 номерлы, 2017 елның 20 гыйнварындагы ПУ-39 номерлы, 2017 елның 8 июнендәге ПУ-480 номерлы, 2018 елның 3 маендагы ПУ-348 номерлы, 2018 елның 19 декабрендәге ПУ-864 номерлы, 2018 елның 28 декабрендәге ПУ-890 номерлы, 2020 елның 18 мартындагы ПУ-177 номерлы һәм 2020 елның 11 августындагы ПУ-470 номерлы, 2021 елның 21 гыйнварындагы ПУ-42 номерлы, 2022 елның 24 августындагы ПУ-590 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 5 июнендәге 385 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасында электр тәэминаты куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча штаб (алга таба шулай ук – Штаб) составында:

Штаб составыннан Р.Җ. Хәбибуллинны, А.В. Хохоринны, И.И. Шәйдуллинны чыгарырга;

Штаб составына кертергә:

Галиева Эльвира Рәкыйп кызын – Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе башлыгы урынбасары вазыйфаларын башкаручыны;

Драгунов Игорь Сергеевичны – Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе башлыгы урынбасарын (кризиска каршы идарә буенча) (килешү буенча);

Кузнецов Артем Александровичны – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы полиция башлыгы урынбасарын (килешү буенча);

б) Татарстан Республикасында электр тәэминаты куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча штаб турында нигезләмәдә:

3.4 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органы» сүзләренә алмаштырырга;

5.1.1 пунктның алтынчы абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы» сүзләрен «республика башкарма хакимияте органы» сүзләренә алмаштырырга;

5.4 пунктның җиденче абзацында «Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары» сүзләрен «Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2024 ел, 03 июль
№ 510